МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
һӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.04.2020 г.Казань № 99/2-пр

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында

“Нәселле терлекчелек турында” 1995 елның 3 августындагы 123-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында” 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” 2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 декабрендәге 1281 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан нәсел терлекчелеге өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын (алга таба - Административ регламент) расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының, Татарстан Республикасының муниципаль районнарында авыл

хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затларына әлеге Боерык белән расланган Административ регламентка таянырга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары Л.Н. Гариповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2020 елның 22 апрелендәге 99/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты (алга таба - Регламент) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда административ процедураларның (гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге, «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында билгеләнгән тикшерүләрне оештыру һәм уздыру үзенчәлекләрен исәпкә алып, әлеге Регламентта каралган тәртиптә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата гамәлгә ашырыла.

## Дәүләт функциясенең аталышы

1.3. Дәүләт функциясе аталышы: Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру (алга таба-дәүләт функциясе, дәүләт күзәтчелеге)

## Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органы исеме

1.4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы башкарма органы – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба-Министрлык).

Министрлык дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү, план буенча тикшерүләр үткәрү планнарын килештерү мәсьәләләре буенча прокуратура органнары белән, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек итә.

## Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруны җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге

1.5. Дәүләт күзәтчелеге түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба - РФ КоАП) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2002, № 1, 1 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Нәселле терлекчелек турында” 1995 елның 3 августындагы 123-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 123-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1995, № 32, 3199 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 473-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 1, 26 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Нәселле терлекчелек турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 1996 елның 6 мартындагы 244 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәте карары, № 244) (Российская газета, 1996, 26 март, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 28, № 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Тикшерүләрнең бердәм реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы

карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе дезидентларына карата план буенча уздырылучы уртак тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 44, 6127 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан алар эш итүендә булган документларны һәм (яки) мәгълүматны тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствора мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, соратып алу һәм аларга үтенечнамәләр җибәрү хакында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба - 323 номерлы РФ Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2016, № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм таләпләрне бозуны булдырмау турында кисәтү төзү һәм юллау, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә каршылыклар бирү һәм аларны карау, андый кисәтүне үтәү турында хәбәрнамә җибәрү кагыйдәләрен раслау хакында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2017, № 8, 1239 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерү кәгазьләрен (контроль мәсьәләләр исемлекләрен) эшләүгә һәм раслауга гомуми таләпләрне раслау турында» 2017 елның 13 февралендәге 177 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2017, № 9, 1359 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствора мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алар эш итүендәге соратып алына торган документлар һәм (яки) мәгълүмат исемлеген раслау турында” 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы күрсәтмәсе (алга таба - РФ Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2016, № 18, № 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында” 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба - Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Россия газетасы, 2009, № 85 боерыгы, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Нәселле терлекчелектә сөт һәм сөт-ит юнәлешләренең продуктивлыгын исәпкә алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 1 февралендәге 25 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 25 номерлы боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене, 2011, № 16, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының "Нәселле терлекчелек өлкәсендәге "Нәселле терлекчелек өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмалар төрләре" кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыкларының үз көчләрен югалтуын тану турында" 2011 елның 17 ноябрендәге 431 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 431 номерлы боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене, 2012, № 17, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, барлыкка килгән алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан планнан тыш тикшерүләр үткәрүне килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба - Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru) 2017, 21 март, бастырып чыккан: 001201703210041);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Сөт һәм сөт-ит юнәлешләрендәге мөгезле эре терлекләрне бонитировкалау тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2010 елның 28 октябрендәге 379 номерлы боерыгы (алга таба - Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 379 номерлы боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене», № 2, 10.01.2011);

"Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында" 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 482 номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4, 45 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык – төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турында нигезләмә (алга таба - Министрлык турында нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0645 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 30 декабрендәге 1281 номерлы карары (алга таба - ТР МКның 1281 номерлы карары) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы) PRAVO.TATARSTAN.RU (2020, 31 гыйнвар).

## Дәүләт күзәтчелеге предметы

1.6. Дәүләт күзәтчелеге предметы - үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның нәселле терлекчелек өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне үтәү (алга таба - мәҗбүри таләпләр) ул.

## Дәүләт күзәтчелеге объектлары

1.7. Дәүләт күзәтчелеге объекты – Татарстан Республикасы территориясендә нәселле терлек үрчетү, селекция максатларында нәселле продукция (материал) җитештерү һәм кулану, шулай ук нәселле терлекчелек өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү белән шөгыльләнүче юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар (алга таба – юридик затлар, шәхси эшкуарлар) эшчәнлеге ул.

## Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда Министрлыкның вазыйфаи затлары өчен хокуклар, бурычлар һәм чикләүләр

1.8. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү уздырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) хезмәт таныклыгын һәм Министрлыкның тикшерү уздыру турындагы боерыгының күчермәсен күрсәтеп, юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан хуҗалык һәм башка төр эшчәнлек алып барганда кулланыла торган территорияләргә, биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру максатларында тоткарлыксыз үтеп керергә, контроль чараларын, техник һәм транспорт чараларын, җайланмаларны һәм материалларны тикшерергә, шулай ук кирәкле тикшеренүләр, сынаулар, үлчәүләр, эзләнүләр, экспертизалар һәм контроль буенча башка чаралар уздырырга;

2) тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча документларны һәм материалларны, шулай ук юридик зат җитәкчесенең, шәхси эшкуарның яисә аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча язмача аңлатмаларын, аның мәҗбүри таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләренең аңлатмаларын соратып алырга;

3) тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча юридик зат җитәкчесе һәм (яки) юридик зат хезмәткәрләре, шәхси эшкуар белән әңгәмәләр үткәрергә;

4) дәүләт күзәтчелеген оештырганда һәм гамәлгә ашырганда тикшерү үткәрелә торган оешма белән граждан-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итәргә;

5) тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы белән расланган исемлеккә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар карамагындагы документларны һәм (яки) мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карары белән билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бушлай соратып алырга, шул исәптән электрон рәвештә дә.

1.9. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) нәселле терлекчелек өлкәсендәге законнарны бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

2) Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын, үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик затның, шәхси эшкуарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

3) тикшерүне министр, министр урынбасары боерыгы нигезендә билгеләнгән вакытта үткәрергә;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын башкарганда гына үткәрергә, күчмә тикшерүне бары тик хезмәт таныклыкларын, министр, министр урынбасарының тикшерү үткәрү турындагы боерыгының күчермәсен һәм, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 5 өлешендә каралган очракта, тикшерү үткәрүне килештерү турындагы документның күчермәсен күрсәткәндә генә үткәрергә;

5) тикшерү уздырганда җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затка, аның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә каршы килмәскә һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

6) тикшерү уздырганда катнашучы җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәки, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагылышлы мәгълүматны һәм документларны тапшырырга;

7) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;

9) ачыкланган хокук бозулар фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә, шул чараларның хокук бозулар авырлыгына тәңгәл булуын, шулай ук аларның кешеләр гомере, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит өчен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре), дәүләт иминлеге өчен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу өчен куркыныч булмавын истә тотарга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймаска;

10) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан шикаять белдергәндә үз гамәлләренең нигезле булуын расларга;

11) тикшерү үткәрүнең 294-ФЗ номерлы Федераль законда, 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында билгеләнгән срокларын үтәргә;

12) юридик заттан, шәхси эшкуардан Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралмаган документлар һәм башка белешмәләр таләп итмәскә.

13) җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның, шәхси эшкуарның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча күчмә тикшерү уздырыр алдыннан аларны әлеге Регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында, ул булган очракта, үткәрелгән тикшерү турында язып куярга.

1.10. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү уздырганда түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) Министрлык исеменнән эш итә торган вазыйфаи затлар вәкаләтләренә кермәгән булса, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук аларны куллануның мәҗбүрилеге Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документлар таләпләренең үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

4) җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктындагы «б» пунктчасында каралган нигездә мондый тикшерүне уздыру очракларыннан тыш, план буенча яисә планнан тыш күчмә тикшерүне гамәлгә ашырырга;

5) тикшерү объектлары булмаган яки тикшерү предметына карамаган документлар, мәгълүмат бирүне таләп итәргә, шулай ук мондый документларның оригиналларын алырга;

6) тикшерүләр, сынаулар, үлчәүләр уздыру өчен продукция үрнәкләрен, үлчәү объектлары пробаларын, аларны сайлап алу беркетмәләрен рәсмиләштермичә, сайлап алырга, тикшерергә; аларны илкүләм стандартлары, үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу кагыйдәләре, тикшерүләр, сынаулар, үлчәүләр

ысуллары, техник регаламентлар яисә алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган башка норматив техник документлар, тикшеренүләр, сынаулар, үлчәү кагыйдәләре һәм ысуллары белән билгеләнгән нормадан артып киткән күләмдә һәм билгеләнгән рәвештә һәм санда сайлап алырга;

7) тикшерү уздыру нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка серне, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, фаш итәргә;

8) тикшерүне билгеләнгән сроклардан арттырып җибәрергә;

9) юридик затларга, шәхси эшкуарларга алар хисабына контроль буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирергә;

10) юридик заттан, шәхси эшкуардан башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары йә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосындагы оешмалар карамагында булган документларны һәм (яисә) мәгълүматны, шул исәптән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган исемлеккә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кертелгән рөхсәт документларын да кертеп, таләп итәргә;

11) юридик заттан, шәхси эшкуардан тикшерү үткәрү датасына кадәр документлар, мәгълүмат бирүне таләп итәргә. Министрлык, тикшерү үткәрү турында боерык кабул ителгәннән соң, кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алырга хокуклы.

## Үзләренә карата дәүләт күзәтчелеге гамәлгә ашырыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары

1.11. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү уздырганда турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) Министрлыктан, аның вазыйфаи затларыннан 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тикшерү предметына карата булган мәгълүматны алырга;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан Министрлык тарафыннан алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган документларны һәм (яки) мәгълүматны Министрлыкка үз инициативасы белән тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешү һәм килешмәве турында күрсәтергә. Үзләренә карата тикшерү уздырылган юридик зат, шәхси эшкуар тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән йә

ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү акты алынганнан соң унбиш көн эчендә тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә тулаем яки аның аерым нигеәләмәләренә карата Министрлыкка язма рәвештә каршылыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый каршылыкларга аларның нигезлелеген раслый торган документларны яки аларның расланган күчермәләрен өстәп бирергә яисә килешенгән вакытта Министрлыкка тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелүче затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин;

6) Министрлыкның вазыйфаи затларының тикшерү уздырганда юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә;

7) Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкилне яисә Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.12. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле тикшерү уздырганда түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан соратып алына торган документларны һәм материалларны, шулай ук тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язма аңлатмаларны билгеләнгән срокларда тапшырырга;

2) Министрлыкның вазыйфаи затларының һәм күчмә тикшерүендә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең эшчәнлекне башкарганда дәүләт күзәтчелеге объекты тарафыннан кулланылучы биналар, төзелмәләр, корылмалар, урыннар территориясенә тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итәргә;

3) тикшерү уздырганда катнашырга яки мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә.

## Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен тасвирлау

1.13. Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерүне уздырган вазыйфаи затлар тарафыннан түбәндәге документлар тутырыла:

1) билгеләнгән форма буенча ике нөсхәдә тикшерү акты. Тикшерү актының үрнәк формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган;

2) тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булса) уздырылган күчмә тикшерү турында язма (тикшерүләрне исәпкә алу журналының формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141номерлы боерыгы белән расланган);

3) 294-ФЗ номерлы Федераль законның $13^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган мәҗбүри таләпләрне бозу, административ хокук бозу очраклары ачыкланган очракта:

4) әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә;

5) әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 10.11 статьясында каралган административ хокук бозу очраклары ачыклаганда, административ хокук бозу турында беркетмә;

юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара аралашмыйча контроль чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча:

6) шәхси эшкуарлар белән үзара аралашмыйча контроль чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисап;

7) ачыкланган хокук бозулар турындагы мәгълүматны дәлилләр белән министрга (министр урынбасарына) җиткерү;

мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар нәтиҗәләре буенча:

8) мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән кисәтү.

Контроль чаралары барышында контроль чарасын үткәрү объекты булган хуҗалык яки башка эшчәнлекнең законнар таләпләрен бозуга бәйле булуы ачыкланган очракта, әгәр аларны ачыклау, булдырмау һәм аларга чик кую мәсьәләләре Министрлык компетенциясенә кермәсә, Министрлык Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органнарына яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына шул хокук бозулар турында мәгълүмат (белешмәләр) җибәрергә тиеш.

Гражданнардан, шул исәптән шщхси эшкуарлардан, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба - мөрәҗәгать итүче) Министрлыкка кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен нигез булган очракта, дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча җавап мөрәҗәгать итүчегә 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

## 2. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләр

**Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру турында мәгълүмат бирү тәртибе**

2.1. Әлеге Регламент Интернет челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла - http://agro.tatarstan.ru.

2.2. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт.

Министрлыкның территориаль органнары - Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең җитештерү-маркетинг бүлекләре (алга таба – Министрлыкның территориаль органнары) (башлыклары, консультантлары) адреслары һәм телефоннары әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

2.3. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне Министрлыкка җибәрү өчен почта адресы: 420014, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт.

Мөрәҗәгатьләрне юллау өчен Министрлыкның электрон адресы: agro@tatar.ru.

2.4. Министрлыкның эш графигы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, җомга – 8.00 сәгатьтән 15.45 сәгатькә кадәр, төшке аш – 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

2.5. Министрлыкның, аның территориаль органнарының урнашкан урыннары, телефоннары, эш графигы турында мәгълүмат түбәндәге телефоннар буенча бирелә:

+7 (843) 221-76-42, +7 (843) 221-76-41;

Министрлыкның рәсми сайтында : http://agro.tatarstan.ru.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

2.6. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар тарафыннан бирелә:

турыдан-туры шәхси кабул итү кысаларында;

язма рәвештә (язма мөрәҗәгатькә, электрон рәвештә мөрәҗәгать итүгә, әгәр мөрәҗәгатьтә почта адресы күрсәтелгән булса);

электрон почта аша (язма мөрәҗәгаткә, электрон рәвештә мөрәҗәгать итүгә, әгәр мөрәҗәгатьтә электрон адрес күрсәтелгән булса).

Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат Министрлыкның, территориаль органнарның гражданнар кабул ителә торган биналарындагы стендларда, Министрлыкның рәсми сайтында - http://agro.tatarstan.ru урнаштырыла һәм норматив закон актларына үзгәрешләр керткән саен яңартыла.

2.7. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау максатларында Министрлыкның рәсми сайтында шулай ук түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

хокук бозуларны профилактикалау буенча ел саен раслана торган программа;

үтәлешен бәяләү дәүләт күзәтчелеге предметы булган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яисә аларның аерым өлешләре, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстлары;

мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затлар, шәхси эшкуарлар өчен мәгълүмат. Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта, мәҗбүри таләпләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларны гамәлгә кертү сроклары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәүне гамәлгә ашыруга һәм тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру, техник чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр урнаштырыла;

дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәҗрибәсен (елга бер тапкырдан да ким түгел) гомумиләштерү, анда мәҗбүри таләпләрне бозуларның аеруча еш очрый торган очраклары күрсәтелергә һәм андый хокук бозуларны кабат булдырмау максатларында юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрелергә тиешле чаралар буенча тәкъдимнәр булырга тиеш.

## Дәүләт күзәтчелеге буенча чаралар үткәргән өчен юридик затлардан һәм шәхси эшкуарлардан түләү алуга юл куймау

2.8. Дәүләт күзәтчелеге чараларын үткәргән өчен, шул исәптән экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәтләре өчен, аларны тикшерү үткәрүгә җәлеп иткән очракта, юридик заттан, шәхси эшкуардан түләү алынмый.

## Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруның сроклары һәм даимилеге

2.9. Һәр тикшерүнең, план буенчамы яки планнан тышмы, документар һәм күчмә тикшерүме, үткәрү вакыты егерме эш көненнән дә артмаска тиеш.

Бер кече эшкуарлык субъектына карата план буенча күчмә тикшерүләр үткәрүнең бер елга гомуми вакыты кече предприятие өчен - илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

Министрлыкның план буенча күчмә тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм эзләнүләр үткәрү зарурлыгына бәйле аерым очракларда, күчмә тикшерүне үткәрү вакыты министр тарафыннан иң күбе егерме эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин, әмма бу кече предприятиеләргә карата - илле сәгатьтән, микропредприятиеләргә карата унбиш сәгатьтән күбрәк булырга тиеш түгел.

Кече эшкуарлык субъектына план буенча тикшерү уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу зарурлыгы булган очракта, министр (министр урынбасары) тикшерү үткәрүне ведомствоара мәгълүмати бәйләнешне гамәлгә ашыру өчен кирәкле срокка, әмма ун эш көненнән дә артмаган вакытка, туктатып торырга мөмкин. Тикшерүне кабат туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрү туктатып торылган чорда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, башка объектларында Министрлыкның күрсәтелгән тикшерүгә бәйле гамәлләре туктатып торыла.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген алып баручы юридик затка карата тикшерү үткәрү вакыты (документар, шулай ук күчмә) юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе буенча аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты алтмыш эш көненнән дә артмаска тиеш

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата план буенча тикшерү үткәрү вакыты аны башлаганнан көннән алып унбиш эш көненнән дә артмый. Кече эшкуарлык субъекты булып торучы алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата план буенча күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты кече предприятие өчен - елга кырык сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен ун сәгатьтән артмаска тиеш. Министрлыкның тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр һәм экспертизалар үткәрү зарурлыгына бәйле аерым очракларда тикшерү үткәрү вакыты озайтыла, әмма бу кече предприятиеләргә карата – утыз сәгатьтән, микропредприятиеләргә карата - ун сәгатьтән һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең башка резидентларына карата унбиш эш көненнән дә артмаска тиеш.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата планнан тыш тикшерү үткәрү вакыты биш эш көненнән дә артмаска тиеш.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата тикшерүләр үткәрү сроклары 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясы таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

## Тикшерүләр уздыру өчен нигезләр

2.10. План буенча тикшерүләр юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата Министрлык тарафыннан ел саен эшләнә һәм раслана торган планнар (алга таба – еллык план) нигезендә уздырыла. Еллык план 294-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 489 номерлы карары нигезендә эшләнә.

2.11. Министр тарафыннан расланган еллык тикшерүләр планы Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

2.12. Еллык планга план буенча тикшерүне кертү өчен түбәндәгедән соң өч ел узган булу кирәк:

1) юридик зат, шәхси эшкуар дәүләт теркәвенә алынганнан соң;

2) юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча соңгы тикшерү уздырылганнан соң.

2.13. Планнан тыш тикшерү уздыру өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бетерү турында элек бирелгән күрсәтмәнең юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан үтәлү срогы тәмамлану;

2) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча тикшереп тору буенча чаралар нәтиҗәләрен анализлау, Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар буенча кергән мәгълүматны карау яисә алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлыкның вазыйфаи затының дәлилләнгән тәкъдиме:

а) гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният ядкарьләренә), дәүләт иминлегенә зыян килү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният ядкарьләренә), дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә һәм прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү уздыру турында прокурор таләбе нигезендә чыгарылган министр урынбасары боерыгы (күрсәтмәсе) булу.

2.14. Министрлыкка мөрәҗәгать иткән затны ачыкларга мөмкин булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге Регламентның 2.13 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләр булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, Бердәм идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында мөрәҗәгать итүченең мәҗбүри авторизацияләнүе каралган мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып җибәрелгән очракта гына, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була ала.

2.15. Әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән фактлар турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны караганда, элегрәк кергән шундый мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата элегрәк үткәрелгән контроль чаралары нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.16. Мәҗбүри таләпләрне бозган зат турында дөрес мәгълүмат булмаганда, әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүмат булмаганда, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан кергән мәгълүматка алдан тикшерү уздырылырга мөмкин. Кергән мәгълүматны алдан тикшерү барышында гариза һәм мөрәҗәгать җибәргән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу буенча чаралар күрелә, Министрлык карамагында булган юридик затның, шәхси эшкуарның документлары

карала. Алдан тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшкуардан алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, әмма мондый аңлатмаларны һәм башка документларны тапшыру мәҗбүри түгел.

2.17. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозган затларны ачыклаганда, әлеге Регламентның 2.13 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында тиешле мәгълүматны алганда Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты әлеге Регламентның 2.13 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилләнгән күрсәтмә әзерли. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшкуарны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

2.18. Тиешле тикшерү башланганнан соң, аны оештыру өчен сәбәп булган мөрәҗәгатьнең яисә гаризаның аноним булуы ачыкланса, йә мөрәҗәгатьтәге яки гаризадагы белешмәләрнең дөрес булмавы билгеләнсә, планнан тыш тикшерү Министр урынбасары карары буенча туктатыла.

2.19. Гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып дөрес булмаган белешмәләр китерелгән очракта, Министрлык гражданнардан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшкуардан кергән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карауга бәйле тотылган чыгымнарны түләттерү турында гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.20. Юридик затларны, шәхси эшкуарларны планнан тыш күчмә тикшерү әлеге Регламентның 2.13 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, мондый юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештерелгәннән соң, уздырылырга мөмкин.

Юридик затны, хосусый эшкуарны планнан тыш күчмә тикшерүне килештерү турында гариза формасы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланды.

2.21. Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очракларын бетерү турындагы күрсәтмәнең юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан үтәлү вакыты чыккан очракта, бары тик Министрлык биргән күрсәтмәне үтәү генә мондый тикшерү предметы булырга мөмкин.

## Дәүләт күзәтчелеген турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар

2.22. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары;

Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы, аңа вазыйфаи регламент нигезендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру йөкләнә;

Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы урынбасары, терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге секторлары мөдирләре һәм әйдәүче киңәшчеләре;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең җитештерү-маркетинг бүлегенең терлекчелек буенча консультантлары.

«Бердәм тикшерүләр реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба - Бердәм тикшерүләр реестры) тиешле мәгълүматны кертү Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.23. Тикшерүләр үткәрүгә үзләренә карата тикшерү уздырыла торган юридик зат, шәхси эшкуар белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм эш-гамәлләре тикшерелүче затларга бәйле (аффилированные) булмаган экспертлар, эксперт оешмалары җәлеп ителергә мөмкин.

## 294-ФЗ номерлы Федераль законны бозган өчен юридик затларның, шәхси эшкуарларның җаваплылыгы

2.24. Тикшерүләр уздырганда юридик затлар - җитәкчеләрнең, башка вазыйфаи затларның яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре булуны тәэмин итәргә, шәхси эшкуарлар үзләре булырга яисә мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләренең булуын тәэмин итәргә тиеш.

2.25. 294-ФЗ номерлы Федераль законны бозган, тикшерүләр уздырудан качып йөрүче һәм (яисә) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында Министрлык күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар яисә юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

## Тикшерү уздырганда Министрлыкның, аларның вазыйфаи затларының җаваплылыгы

2.26. Министрлык, аларның вазыйфаи затлары тикшерү уздырганда тиешле функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән, хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

2.27. Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата кабул ителгән чаралар турында, мондый чаралар кабул ителгән көннән ун көн эчендә Министрлык хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшкуарга язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 3. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата куела торган мәҗбүри таләпләр

3.1. Үтәлеше Министрлык тарафыннан контрольдә тотыла торган юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата куелган мәҗбүри таләпләр исемлеге, мәҗбүри таләпләрне билгели торган норматив хокукый актлар күрсәтелеп, әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелде.

3.2. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең бозылуын кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү максатларында, Министрлык ел саен үзе раслый торган хокук бозуларны профилактикалау программасы нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыра.

3.3. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау максатларында Министрлык юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 5-7 өлешләрендә билгеләнгән тәртип нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куелмау турында кисәтүләр ясый һәм юридик затка, шәхси эшкуарга мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта Министрлыкка билгеләнгән срокта хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү төзү һәм җибәрү, контроль объекты тарафыннан мондый кисәтүгә каршылыклар бирү һәм аларны Министрлык тарафыннан карау, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Министрлыкка мондый кисәтүнең үтәлүе турында хәбәр итү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 166 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар

Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздырганда вазыйфаи затлар тикшерелә торган юридик затның, шәхси эшкуарның үзеннән таблицада күрсәтелгән документларны соратып ала.

Таблица

**Тикшерү уздыру максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге**

| Тикшерү үткәрү өчен тапшырыла торган документ | Документ формасын билгеләүче норматив хокукый акт |
|---|---|
| 1) Нәсел оешмасы статусын раслый торган, дәүләт нәсел регистрында теркәлү турында таныклык | Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының Нәселле терлекләрне дәүләт теркәвенә алу һәм дәүләт нәсел регистрын алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча 2011 елның 24 октябрендәге 377 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Административ регламентының 11 пункты |

| | |
|---|---|
| 2) Предприятиенең штат расписаниесе | РФ Дәүләт статистика комитетының 05.01.2004 № 1 карары белән расланган, унификацияләнгән № Т-3 формасы |
| 3) Оешманың структурасы | Оешма боерыгы нигезендә ирекле форма |
| 4) Селекция эшенең планы | Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 17.11.2011 № 431 Боерыгы белән расланган Нәселле терлекчелек өлкәсендәге кагыйдәләрнең 10 пункты: “Нәселле терлекчелек өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар төрләре” |
| 5) Тикшерү елы алдындагы елда бонитировкалау | Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 28.10.2010 № 379 Боерыгы |
| 6) Нәсел таныклыкларының күчермәләре | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 07.12.2017 № 282/2-пр Боерыгы: “Нәсел продукциясенә (материалына) нәсел таныклыклары бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты” |
| 7) Төп чаралар исемлеге | Россия Федерациясе Дәүләт статистика комитетының 21.01.2003 № 7 карары белән расланган ОС-6 формасы |

## 5. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре

### Административ процедуралар исемлеге

5.1. Дәүләт күзәтчелеге юридик затларны, шәхси эшкуарларны тикшерүне оештыру һәм уздыру, мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чаралар (әлеге Регламентның 3.2 - 3.4 пунктлары), юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара аралашмыйча контроль чараларын оештыру һәм уздыру, ачыкланган бозуларның нәтиҗәләрен бетерү һәм (яки) аларга чик кую буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чаралар күрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга түбәндәге административ процедуралар керә:

план буенча тикшерүләр үткәрүне планлаштыру;

юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча документар тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү;

юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча күчмә тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү;

юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү;

юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү;

юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара аралашмыйча контроль чараларын уздыру.

5.2. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруның Блок-схемасы әлеге Регламентка 5 нче кушымтада китерелгән.

Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруны туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда рөхсәт ителә.

## “План буенча тикшерүләр уздыруны планлаштыру” административ процедурасы

5.3. Административ процедураны башлау өчен еллык планны әзерләү сроклары килеп җитү нигез булып тора.

5.4. Тикшерүләр планы бүлек тарафыннан 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнә. Еллык планны әзерләү тәртибе һәм сроклары, шул исәптән аны прокуратура органнарына тапшыру һәм прокуратура органнары белән килештерү тәртибе, шулай ук еллык планның үрнәк формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 489 номерлы карары белән расланган Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны план буенча тикшерү планнарын дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан әзерләү кагыйдәләре белән билгеләнә.

Еллык тикшерүләр планына план буенча тикшерүне кертү өчен әлеге Регламентның 2.11 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

Еллык тикшерүләр планнарын төзегәндә, еллык тикшерүләр планнарын әзерләү буенча җаваплы башкаручы, кирәк булганда, билгеләнгән тәртиптә аларны төзү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасы нигезендә соратып ала.

5.5. Еллык тикшерүләр планнарын әзерләү буенча җаваплы башкаручы министр раслаган еллык тикшерүләр планын Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыруны оештыра.

Үтәү срогы: Татарстан Республикасы Прокуратурасы сайтында Еллык еллык бердәм тикшерүләр планы урнаштырылганнан соң, 5 эш көненнән дә соңга калмыйча.

5.6. Еллык тикшерүләр планына үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 489 номерлы карары белән билгеләнгән очракларда рөхсәт ителә (Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм

дәүләт реестрыннан юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу, аны бетерү (реестрдан төшереп калдыру) турындагы язма кертелү турында өземтә).

Еллык тикшерүләр планына үзгәрешләр кертү министр боерыгы белән башкарыла. Кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр билгеләнгән тәртиптә тиешле прокуратура органына кертелгән көннән өч эш көне эчендә җибәрелә һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла

## “Юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча документар тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү” административ процедурасы

### Административ процедураны башлау өчен нигез, административ гамәлләр тәртибе

5.7. «Юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча документар тикшерү уздыру, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасын башлау өчен еллык тикшерүләр планы нигезендә юридик затка, индивидуаль эшкуарга план буенча документар тикшерү уздыру срокларының җитүе нигез була.

“Юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча документар тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү” административ процедурасы түбәндәге административ гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла:

тикшерү уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

тикшерү уздыру турында боерыкны рәсмиләштерү;

тикшерү уздыру турында юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итү;

тикшерү уздыру;

тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү;

тикшерү нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат урнаштыру.

### Тикшерү уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү

5.8. Еллык тикшерүләр планы нигезендә бүлек башлыгы әлеге Регламентның 2.22 пункты нигезендә юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү уздыру өчен вәкаләтле вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү срогы: тикшерү башланганчы ун эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: юридик затны, шәхси эшкуарны тикшерү өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

**Тикшерү уздыру турындагы боерыкны рәсмиләштерү**

5.9. Җаваплы башкаручы:

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча документар тикшерү уздыру турында боерык проектын әзерли, боерыкның эчтәлеге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш;

боерык проектын министрга, министр урынбасарына имзалау өчен җибәрә.

Үтәү срогы: тикшерү башланганчы җиде эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча документар тикшерү уздыру турында министр урынбасары тарафыннан имзаланган боерык.

**Тикшерү уздыру турында юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итү**

5.10. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча тикшерү уздыру турында министр, министр урынбасары боерыгының күчермәсен почта аша, аның тапшырылуы турында хәбәрнамә бирүне күрсәтеп, заказлы юллама итеп җибәрә һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документны юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почтасы адресы буенча җибәрә, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән булса йә юридик зат, шәхси эшкуар элегрәк Министрлыкка тапшырган булса, яки мөмкин булган башка ысул белән җибәрә.

Юридик зат, шәхси эшкуар - үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасы тикшерелә торган очракта, җаваплы башкаручы шулай ук, план буенча документар тикшерү уздырганда, аның вәкиленең катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, үз-үзен җайга салучы оешмага да хәбәрнамә җибәрә.

Үтәү срогы: тикшерү башланганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эшчәнлек нәтиҗәсе: план буенча документар тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән боерык күчермәсе һәм үз-үзен җайга салучы оешмага җибәрелгән хәбәрнамә (үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасына тикшерү үткәрелгән очракта)

5.11. Юридик зат, шәхси эшкуар боерыкның күчермәсен алганнан соң ун эш көне эчендә Министрлыкка план буенча документар тикшерү уздыру турындагы боерыкта күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

Күрсәтелгән документлар шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче, юридик затның башка вазыйфаи заты имзасы һәм мөһер белән (булса) танылган күчермәләр рәвешендә тапшырыла.

Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, Министрлыкка тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.

Министрлык юридик заттан, шәхси эшкуардан дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органнарыннан Министрлык тарафыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

Җаваплы башкаручы тикшерү уздыру турында боерык кабул ителгәннән соң юридик заттан, шәхси эшкуардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

Министрлык тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы белән расланган исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан алар карамагындагы әлеге документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә соратып ала (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта).

## Тикшерү уздыру

5.12. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар, Министрлык карамагындагы документларда булган белешмәләр һәм юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган документлардагы белешмәләр нигезендә:

- белешмәләрнең дөреслеген бәялиләр;
- документларда булган белешмәләрне юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәвенә бәялиләр.

Документар тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшкуар тапшырган документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланган яки бу документлардагы белешмәләрнең Министрлыкта булган документлардагы белешмәләргә туры килмәве ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы:

- белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат белән һәм, ун эш көне эчендә язма рәвештә кирәкле аңлатмалар бирүне таләп итеп, юридик затка, шәхси эшкуарга хат (дәлилле гарызнамә) әзерли;
- хатны (дәлилле гарызнамәне) министрга, министр урынбасарына имзалау өчен җибәрә;
- имзаланганнан соң хатны (дәлилле гарызнамәне) юридик затка, шәхси эшкуарга почта аша, аның тапшырылуы турында хәбәрнамә бирүне күрсәтеп, заказлы юллама итеп җибәрә йә мөмкин булган башка ысул белән (факсимиль элемтә, электрон почта, кулдан-кулга тапшыру, алу турында тамга белән) җибәрә.

Тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата яисә әлеге документлардагы белешмәләрнең Министрлыкта

булган документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә карата Министрлыкка аңлатмалар бирүче юридик зат, индивидуаль эшкуар, элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган өстәмә документларны Министрлыкка тапшырырга хокуклы.

Аңлатмалар һәм (яки) элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документлар алынганнан соң, тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) документларны карый. Мәҗбүри таләпләр бозылмаган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү актын төзи.

Тапшырылган аңлатмаларны һәм документларның дөреслеген раслый торган документларны караганнан соң йә аңлатмалар булмыйча Министрлык мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләрен ачыкласа, вазыйфаи затлар күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы, аны үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү барышында алар тапшырган документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшыруны таләп итү тыела.

Бу очракта документар тикшерү нәтиҗәсе «Юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасын башкару өчен нигез булып тора.

Күчмә тикшерүне уздыру турындагы карарны министр йә аның урынбасары кабул итә.

Үтәү срогы: тикшерү уздыру турындагы боерык белән һәм әлеге Регламентның 2.9 пункты нигезендә билгеләнгән срок дәвамында.

Эш нәтиҗәсе:

контроль буенча үткәрелгән чаралар;

мәҗбүри таләпләрнең бозылган булуын яисә булмавын ачыклау;

кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында боерык проекты.

## Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү

5.13. Тапшырылган документларны һәм мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә тикшерү актын төзи.

Контрольдә тоту чаралары нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы түбәндәге гамәлләрне башкара:

ачыкланган хокук бозу очракларының барысын да тикшерү актында терки;

ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, юридик затка, шәхси эшкуарга күрсәтмә бирә;

ачыкланган хокук бозуларны бетерүне, аларны кисәтүне контрольдә тоту, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә;

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 10.11 статьясында каралган административ хокук бозулар билгеләре ачыкланганда, аларны билгеләнгән тәртиптә карауны тәэмин итә.

Контроль чаралары барышында контроль чарасын башкару объекты булган хуҗалык яки башка эшчәнлекнең закон таләпләрен бозуга бәйле булуы ачыкланган, аларны ачыклау, булдырмау һәм аларга чик кую мәсьәләләре Министрлык компетенциясенә кермәгән очракта, Министрлык мондый хокук бозулар турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органнарына мәгълүмат (белешмәләр) җибәрергә тиеш.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарның күчермәләре белән бергә) җаваплы башкаручы эшнамәгә тегеп куя һәм аны билгеләнгән тәртиптә Министрлык архивына тапшырганчы саклый, икенчесен (кушымталарның күчермәләре белән бергә) җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә, тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында расписка белән, тапшыра.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы турындагы расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт почта аша, аның тапшырылуы турында хәбәрнамә бирүне күрсәтеп, заказлы юллама итеп җибәрелә, ул Министрлык эшнамәсендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлеп куела. Тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында үзара электрон рәвештә аралашуга ризалыгы булганда, тикшерү акты әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Мондый чакта әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән электрон документ рәвешендә тикшерелә торган затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип санала. Тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яки) актны алуны башкача раслау Министрлык эшнамәсендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Үзләренә карата тикшерү уздырылган юридик зат, шәхси эшкуар тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән йә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү акты алынганнан соң унбиш көн эчендә тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә тулаем яки аның аерым нигезләмәләренә карата Министрлыкка язма рәвештә каршылыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый каршылыкларга аларның нигезлелеген раслый торган документларны яки аларның расланган күчермәләрен өстәп бирергә яисә килешенгән вакытта Министрлыкка тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелүче затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Үтәү срогы:

тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамлануга (әгәр тикшерү актын төзү өчен уздырылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус эзләнүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булса, очракта, тикшерү акты контроль чаралары тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә артмаган срок эчендә төзелә);

җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы турындагы расписка бирүдән баш тарткан очракта, актны почта аша, аның тапшырылуы турында хәбәрнамә бирүне күрсәтеп, заказлы юллама итеп йә тикшерү актын әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрү: тикшерү акты төзелгән көннән соң бер эш көне эчендә;

тикшерү актын ул төзелгән урындагы Бүлектә саклау: 5 ел дәвамында, аны билгеләнгән тәртиптә Министрлык архивына тапшырганчы.

Эш нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырыла (җибәрелә), икенчесе тикшерү акты төзелгән урындагы Бүлектә билгеләнгән тәртиптә эшнамәгә тегелә.

5.14. Тикшерелүче субъект тарафыннан нәселле терлекчелек өлкәсендәге законнар бозылу факты күрсәтелгән тикшерү акты ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү өчен нигез була.

Тикшерүне уздырган җаваплы башкаручы, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында билгеләнгән форма нигезендә ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча һәм (яки) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль милеккә зыян китерүне булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең барлыкка килүен кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар уздыру турында, аларның срокларын күрсәтеп, күрсәтмә әзерли.

Күрсәтмәдә нәселле терлекчелек өлкәсендәге законнар таләпләрен бетерү срогы күрсәтелә (күрсәтмәне үтәү срогы).

Күрсәтмә тикшерү тәмамлануга тикшерү акты төзү белән бер үк вакытта төзелә һәм тикшерү актына кушымта булып тора.

Күрсәтмә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән бергә расписка белән тапшырыла.

Җаваплы башкаручы ачыкланган хокук бозуларны бетерүне контрольдә тоту, аларны кисәтү, гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүне булдырмау, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә.

5.15. Тикшерү барышында Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында җаваплылык каралган хокук бозулар ачыкланган очракта, административ хокук бозулар турында беркетмә төзергә вәкаләтле вазыйфаи зат Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозу турында беркетмә төзи.

Административ хокук бозу турында беркетмә тикшерү урынында административ хокук бозу факты ачыкланганнан соң кичекмәстән төзелә. Эш торышын өстәмә ачыклау таләп ителгән очракта, административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозу ачыкланганнан соң ике эш көне эчендә төзелә.

Административ хокук бозу турында беркетмә Административ хокук бозулар турында РФ кодексында каралган тәртиптә административ хокук бозу турындагы эшне карау өчен судка җибәрелә.

Юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан нәселле терлекчелек өлкәсендәге законнар таләпләрен бозу карар кабул итү критерие булып тора.

Эш нәтиҗәсе: административ хокук бозу турында беркетмә төзү һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү.

## Тикшерү нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат урнаштыру

5.16. Административ процедура тәмамланганнан соң, җаваплы башкаручы план буенча документар тикшерү нәтиҗәсен теркәү максаты белән Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру өчен тиешле мәгълүмат җибәрә.

Үтәү срогы: мәгълүмат урнаштыру - тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эш нәтиҗәсе: план буенча документар тикшерү нәтиҗәләре турында Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүмат.

5.17. Вәкаләтле вазыйфаи зат тиешле мәгълүматны 294-ФЗ номерлы Федераль законның $13^3$ 133 статьясы һәм РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә Бердәм тикшерүләр реестрына кертә.

## “Юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча күчмә тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү” административ процедурасы

### Административ процедураны башлау өчен нигез, административ гамәлләр тәртибе

5.18. “Юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча күчмә тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү” административ процедурасын башлау өчен юридик затны, индивидуаль эшкуарны еллык тикшерүләр планы нигезендә план буенча күчмә тикшерүне уздыру сроклары җитү нигез булып тора, шулай ук. әгәр дә документар тикшерү барышында түбәндәгеләрне башкару мөмкин булмаса, әлеге процедураны башлау өчен сәбәп була:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамәдә булган белешмәләрнең һәм юридик затның, шәхси эшкуарның

Министрлык карамагындагы башка документларының тулылыгына һәм дөреслегенә ышану;

2) тиешле контроль чараларын уздырмыйча, юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү мөмкин булмаса.

“Юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча күчмә тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү” административ процедурасы әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

## Тикшерү уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү, тикшерү уздыру турында боерыкны рәсмиләштерү, юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү уздыру турында хәбәр итү

5.19. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгеләү, план буенча күчмә тикшерү уздыру турында боерык әзерләү, юридик затка, шәхси эшкуарга план буенча күчмә тикшерү уздыру турында хәбәр итү, үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасына тикшерү уздырган очракта, үз-үзен җайга салучы оешмага хәбәр итү әлеге Регламентның 5.8 – 5.10 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## Тикшерү уздыру

5.20. План буенча күчмә тикшерү юридик зат урнашкан урында, шәхси эшкуарның эшчәнлек алып бару урынында һәм (яки) аларның эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны буенча үткәрелә.

5.21. Вазыйфаи затлар тикшерү объектына килеп җиткәннән соң, тикшерүне түбәндәгедән башлыйлар:

Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан хезмәт таныклыкларын күрсәтү;

җитәкчене, башка вазыйфаи затны яисә юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен катгый рәвештә түбәндәгеләр белән таныштырудан:

министрның (министр урынбасарының) план буенча күчмә тикшерүне билгеләү турында боерыгы;

күчмә тикшерүне уздыручы затларның вәкаләтләре;

күчмә тикшерүне уздыруның максатлары, бурычлары, нигезләре;

контроль буенча чаралар төрләре һәм күләме;

экспертлар составы, күчмә тикшерүгә җәлеп ителгән эксперт оешмалары вәкилләре;

аны уздыру вакыты һәм шартлары;

җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү уздыру турындагы боерыкның мөһер белән танытылган күчермәсен кул куйдырып тапшыру.

Үтәү срогы: тикшерү уздыру урынына килеп җитүгә.

5.22. Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча вазыйфаи затлар үз вәкаләтләрен раслау максатларында Министрлык турында, шулай ук экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә тиеш.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча вазыйфаи затлар тикшерелергә тиешле затларны әлеге Регламент белән таныштырырга тиеш.

5.23. Тикшерү барышында вазыйфаи затлар:

тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документларда булган белешмәләрне өйрәнәләр;

тикшерелүче зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерәләр (әлеге Регламентның 3 бүлеге нигезендә);

кирәк булганда, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча документлар һәм (яки) мәгълүмат соратып алалар, шулай ук җитәкченең, башка вазыйфаи затларның яки тикшерелүче затның вәкаләтле вәкиленең язмача аңлатмаларын соратып алалар, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча җитәкче һәм (яки) хезмәткәрләр белән әңгәмәләр үткәрәләр;

тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча тапшырылган документларны, материалларны һәм аңлатмаларны анализлыйлар һәм мәҗбүри таләпләрне бозу (бозмау) турында карар кабул итәләр;

бозу фактларын раслый торган документлар (алга таба - раслый торган документлар) күчермәләрен әзерлиләр һәм билгеләнгән тәртиптә раслыйлар;

мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында белешмәләрне тикшерү актына кертәләр, раслый торган документларның күчермәләрен шуңа өстәп куялар.

Үтәү срогы: әлеге Регламентның 2.9 пункты нигезендә.

Эш нәтиҗәсе: контроль буенча үткәрелгән чаралар;

мәҗбүри таләпләрнең бозылу яисә бозылмау очракларын ачыклау.

5.24. План буенча тикшерү уздырганда Министрлыкның вазыйфаи затлары тикшерү кәгазьләреннән (контроль сораулар исемлегеннән) файдаланырга тиеш.

Тикшерү кәгазьләреннән (контроль сораулар исемлекләреннән) файдалану барлык юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны план буенча тикшерү барышында гамәлгә ашырыла.

План буенча тикшерү уздырганда кулланыла торган тикшерү кәгазьләрендә (контроль сораулар исемлекләрендә) юридик затка һәм шәхси эшкуарга карата куела торган мәҗбүри таләпләргә кагылышлы мәсьәләләр була, аларны үтәү гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннар сәламәтлегенә, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният ядкарьләренә), дәүләт иминлегенә куркыныч янауны, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән куркыныч янауны булдырмау ягыннан аеруча әһәмиятле

Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны план буенча тикшерү предметы тикшерү кәгазьләренә (контроль сораулар исемлегенә) кертелгән мәсьәләләр исемлеге белән чикләнә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) тикшерү актына теркәлә.

5.25. Салым серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алу ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тиешле белешмәләрне тикшерү юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлү фактын билгеләү зарурлыгына бәйле һәм әлеге белешмәләрне бирү Федераль законда каралган очракта рөхсәт ителә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат тапшыру, аларны ачу, шул исәптән 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда алар белән танышу дәүләт сере һәм башка саклана торган сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

5.26. Шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче яки юридик затның бүтән вазыйфаи заты булмау яисә юридик зат, шәхси эшкуар үз эшчәнлеген фактта башкармауга бәйле йә индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, җитәкченең яисә юридик затның бүтән вазыйфаи затының башка гамәлләренә (гамәл кылмауларына) бәйле, яисә башка юридик затның тикшерү уздыру мөмкинлеген бирмәгән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) бәйле рәвештә план буенча яисә планнан тыш күчмә тикшерүне уздырып булмаган очракта, вазыйфаи зат, аны уздыру мөмкинлеге булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне уздыруның мөмкин булмавы турында акт төзи. Бу очракта Министрлык тиешле тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турындагы акт төзелгәннән соң өч ай эчендә, план буенча тикшерүне план буенча тикшерүләрнең еллык планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә генә, мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата план буенча тикшерү уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

## Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү

5.27. Контроль буенча уздырылган чаралар нигезендә җаваплы башкаручы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә тикшерү акты төзи.

Мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерү актында ачыкланган барлык хокук бозулар очраклары теркәлә һәм тикшерү актына түбәндәгеләр өстәмә итеп бирелә:

мәҗбүри таләпләрнең бозылу фактларын раслый торган документлар күчермәләре;

юридик зат хезмәткәрләренең, шәхси эшкуарның һәм (яки) аның мәҗбүри таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган хезмәткәрләренең аңлатмалары;

ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмә, үтәү срокларын күрсәтеп;

тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге);

тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре.

Җаваплы башкаручы тикшерү уздырган вазыйфаи затлар белән бергә 2 нөсхәдә тикшерү актына кул куя.

Тикшерү барышында мәҗбүри таләпләрне яки Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында административ җаваплылык каралган башка хокук бозулар ачыкланган очракта, тикшерүне уздырган вазыйфаи затлар әлеге Регламентның 5.14 - 5.15 пунктлары нигезендә күрсәтмә чыгарыла яисә административ хокук бозу турында беркетмә төзелә.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарның күчермәләре белән бергә) җаваплы башкаручы эшнамәгә тегеп куя һәм аны билгеләнгән тәртиптә Министрлык архивына тапшырганчы саклый, икенчесен (кушымталарның күчермәләре белән бергә) җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә, тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында расписка белән, тапшыра.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат тикшерү акты белән танышуы яки танышудан баш тартуы турындагы расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт почта аша, аның тапшырылуы турында хәбәрнамә бирүне күрсәтеп, заказлы юллама итеп җибәрелә, ул Министрлык эшнамәсендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлеп куела. Тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында үзара электрон рәвештә аралашуга ризалыгы булганда, тикшерү акты әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Мондый чакта әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән электрон документ рәвешендә тикшерелә торган затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип санала. Тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яки) актны алуны башкача раслау Министрлык эшнамәсендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Тикшерү актын төзү өчен уздырылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус эзләнүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булган очракта, тикшерү акты контроль чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә артмаган срок эчендә төзелә һәм җитәкчегә расписка белән тапшырыла йә почта аша, аның тапшырылуы турында хәбәрнамә бирүне күрсәтеп, заказлы юллама итеп җибәрелә яки (тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) яисә муниципаль контроль кысаларында үзара электрон рәвештә аралашуга ризалыгы булганда) тикшерү акты әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә әлеге документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелә. Тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яки) актны алуны башкача раслау Министрлык эшнамәсендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Үзләренә карата тикшерү уздырылган юридик зат, шәхси эшкуар тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән йә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү акты алынганнан соң унбиш көн эчендә тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә тулаем яки аның аерым

нигезләмәләренә карата Министрлыкка язма рәвештә каршылыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый каршылыкларга аларның нигезлелеген раслый торган документларны яки аларның расланган күчермәләрен өстәп бирергә яисә килешенгән вакытта Министрлыкка тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелүче затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Үтәү срогы:

тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганга;

актны заказлы хат белән йә әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

тикшерү актын аны төзегән урындагы Бүлектә саклау: норматив актларда билгеләнгән сроклар дәвамында, аны билгеләнгән тәртиптә Министрлык архивына тапшырганчы.

Эш нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аларның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшнамәгә тегелгән һәм төзегән урындагы Бүлектә билгеләнгән тәртиптә саклана.

5.28. Мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган хокук бозуларны бетерү, аларны кисәтү, шулай ук гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә.

Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзаларының мәҗбүри таләпләрне бозулары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә ачыкланган хокук бозулар турында үз-үзен җайга салучы оешмага хәбәрнамә җибәрә.

## Тикшерү нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат урнаштыру

5.29. Җаваплы башкаручы юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булса) план буенча уздырылган тикшерү нәтиҗәләре турында язып куя, анда дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының исеме, тикшерү уздыруны башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү срогы, хокукый нигезләр, тикшерү максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган хокук бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләр, шулай ук тикшерүне уздыручы затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исеме, вазыйфалары күрсәтелә һәм аларның имзалары куела.

Үтәү срогы: тикшерү тәмамлануга.

Эш нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булса) план буенча күчмә тикшерү уздыру турындагы язма.

5.30. Административ процедура тәмамланганнан соң, җаваплы башкаручы план буенча күчмә тикшерү нәтиҗәсен теркәү максатында Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру өчен тиешле мәгълүмат җибәрә.

Үтәү срогы: тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча мәгълүмат урнаштыру.

Эш нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган план буенча тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.31. Вәкаләтле вазыйфаи зат тиешле мәгълүматны 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә Бердәм тикшерүләр реестрына кертә.

## “Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү” административ процедурасы

### Административ процедураны башлау өчен нигез, административ гамәлләр тәртибе

5.32. «Юридик затка, индивидуаль эшкуарга планнан тыш документар тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасын башлау өчен, әгәр Россия Федерациясе норматив актларында башкасы каралмаган булса, әлеге Регламентның 2.13 пунктындагы икенче, дүртенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

5.33. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

### Тикшерү уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү

5.34. Тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү әлеге Регламентның 2.13 пунктындагы дүртенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән нигезләр барлыкка килгән очракта, Бүлек башлыгы министр, министр урынбасары йөкләмәсе нигезендә юридик затны, шәхси эшкуарны тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгеләп куя.

Үтәү срогы: тикшерү уздыру турында боерык чыкканнан соң бер эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү уздыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

Элек бирелгән күрсәтмәнең үтәлү вакыты чыккан очракта, күрсәтмәне биргән җаваплы башкаручы тикшерү уздыра.

### Тикшерү уздыру турындагы боерыкны рәсмиләштерү

5.35. Юридик затка, шәхси эшкукарга планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы Министрлык боерыгын әзерләү әлеге Регламентның 5.9 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Үтәү срогы: планнан тыш документар тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларны билгеләгәннән соң бер эш көне эчендә йә йөкләмәдә күрсәтелгән срок нигезендә.

Эш нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкукарга планнан тыш документар тикшерү уздыру турында министр, министр урынбасары боерыгы.

## Юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү уздыру турында хәбәр итү

5.36. Җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 5.46 пункты нигезендә планнан тыш тикшерү уздыру турында юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итә.

5.37. Юридик зат, шәхси эшкуар боерык күчермәсен алганнан соң ун эш көне эчендә Министрлыкка планнан тыш документар тикшерү уздыру турындагы боерыкта күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

Күрсәтелгән документлар шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче, юридик затның башка вазыйфаи заты имзасы һәм мөһере белән (ул булса) таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла.

Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, Министрлыкка тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.

Министрлык юридик заттан, шәхси эшкуардан башка дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан Министрлык тарафыннан алырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

Җаваплы башкаручы тикшерү уздыру турында боерык кабул ителгәннән соң юридик заттан, шәхси эшкуардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

Министрлык тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы белән расланган исемлеккә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар карамагындагы документларны һәм (яки) мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карары белән билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бушлай соратып ала, шул исәптән электрон рәвештә дә.

## Тикшерү уздыру

5.38. Тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшкуар документларындагы белешмәләрне бәяләү, юридик затның, шәхси эшкуарның әлеге Регламентның 5.12 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелгән искәрмәләргә аңлатмаларын карау гамәлгә ашырыла.

Үтәү срогы: әлеге Регламентның 2.9 пункты нигезендә тикшерү уздыру турындагы боерык белән билгеләнгән тикшерү уздыру срогы дәвамында.

Тикшерү үткәрү

контроль буенча үткәрелгән чаралар;

мәҗбүри таләпләрне бозуларның булуын яисә булмавын ачыклау;

кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында боерык проекты.

## Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү

5.39. Тапшырылган документларны һәм мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 5.13 пункты нигезендә Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә тикшерү актын төзи.

5.40. Мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган хокук бозуларны бетерү, аларны кисәтү, шулай ук гаепле затларны әлеге Регламентның 5.13 – 5.15 пунктлары нигезендә административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә.

Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үз-үзен җайга салчы оешмага хәбәрнамә җибәрә.

## Тикшерү нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат урнаштыру

5.41. Административ процедура тәмамланганнан соң, җаваплы башкаручы план буенча планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәсен теркәү максатында Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру өчен тиешле мәгълүмат җибәрә.

Үтәү срогы: тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча мәгълүмат урнаштыру.

Эш нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.42. Вәкаләтле вазыйфаи зат тиешле мәгълүматны 294-ФЗ номерлы Федераль законның $13^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә Бердәм тикшерүләр реестрына кертә.

## “Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү уздыру, ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрү” административ процедурасы

### Административ процедураны башлау өчен нигез, административ гамәлләр тәртибе

5.43. «Юридик затка, индивидуаль эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасын башлау өчен, әгәр Россия Федерациясе норматив актларында башкасы каралмаган булса, әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

Күчмә тикшерү документар тикшерү вакытында түбәндәгеләрне башкару мөмкин булмаган очракта уздырыла:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамәдә булган белешмәләрнең һәм юридик затның, шәхси эшкуарның Министрлык карамагындагы башка документларының тулылыгына һәм дөреслегенә ышанырга;

2) юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең тиешле контроль чараларын үткәрмичә генә мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләргә.

«Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү уздыру, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

### Тикшерү уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү

5.44. Тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларны, җаваплы башкаручыны билгеләү әлеге Регламентның 5.34 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

### Тикшерү уздыру турындагы боерыкны рәсмиләштерү

5.45. Министрның, министр урынбасарының юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерыгын әзерләү әлеге Регламентның 5.35 пунктында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

### Юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү уздыру турында хәбәр итү

5.46. Җаваплы башкаручы, үткәрү нигезләре әлеге Регламентның 2.13 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерү уздырудан тыш, юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында теләсә нинди мөмкин булган ысул белән хәбәр итә, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның электрон почтасы адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә дә, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса йә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына тәкъдим ителгән булса.

Әлеге Регламентның 2.13 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерү турындагы гариза Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган гаризаның үрнәк формасы нигезендә төзелә.

Юридик затны, шәхси эшкуарны - үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасын тикшергән очракта, җаваплы башкаручы, планнан тыш күчмә тикшерү уздырганда, аның вәкиленең катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, шулай ук үзен-үзе җайга салучы оешмага да хәбәр итә.

Үтәү срогы: тикшерү башланганчы кимендә егерме дүрт сәгать кала.

Эш нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга (һәм үз - үзен җайга салучы оешмага - үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасына тикшерү үткәрелгән очракта) планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында хәбәрнамә.

## Тикшерү уздыру

5.47. Күчмә тикшерүне уздыру әлеге Регламентның 5.7 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Үтәү срогы: әлеге Регламентның 2.9 пункты нигезендә план буенча күчмә тикшерү үткәрү турында боерык белән билгеләнгән тикшерү уздыру срогында.

Эш нәтиҗәсе: үткәрелгән контроль чаралары.

5.48. Әлеге Регламентның 5.26 пунктында күрсәтелгән сәбәпләр аркасында планнан тыш күчмә тикшерүне уздыру мөмкин булмаса, җаваплы башкаручы, сәбәпләрен күрсәтеп, тикшерү уздыру мөмкинлеге турында акт төзи һәм әлеге Регламентның 5.26 пункты нигезендә гамәлләрне башкара.

## Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү

5.49. Тикшерү актын төзү, юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү акты тапшыру әлеге Регламентның 5.27 пункты нигезендә башкарыла

Үтәү срогы:

тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганга (әгәр тикшерү актын төзү өчен уздырылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус эзләнүләр,

экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булса, тикшерү акты контроль чаралары тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә артмаган срок эчендә төзелә);

актны заказлы хат белән йә әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

тикшерү актын аны төзегән урындагы Бүлектә саклау: норматив актларда билгеләнгән сроклар дәвамында, аны билгеләнгән тәртиптә Министрлык архивына тапшырганчы.

Эш нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аларның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшнамәгә тегелгән һәм төзегән урындагы Бүлектә билгеләнгән тәртиптә саклана.

5.50. Мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган хокук бозуларны бетерү, аларны кисәтү, шулай ук гаепле затларны әлеге Регламентның 5.13 – 5.15 пунктлары нигезендә административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә.

Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы үз-үзен җайга салучы оешмага тикшерү тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган хокук бозулар турында хәбәрнамә җибәрә.

**Тикшерү нәтиҗәләре турында тиешле мәгълүмат урнаштыру**

5.51. Җаваплы башкаручы юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булса) планнан тыш күчмә тикшерү нәтиҗәләре турында язып куя, анда дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының исеме, тикшерү уздыруны башлау һәм тәмамлау даталары, аны уздыру срогы, хокукый нигезләр, тикшерү максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган хокук бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләр, шулай ук тикшерүне уздыручы затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исеме, вазыйфалары күрсәтелә һәм аларның имзалары куела.

Үтәү срогы: тикшерү тәмамлануга.

Эш нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булса) планннан тыш күчмә тикшерү уздыру турындагы язма.

5.52. Административ процедура тәмамланганнан соң, җаваплы башкаручы планнан тыш күчмә тикшерү нәтиҗәсен теркәү максатында Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру өчен тиешле мәгълүмат җибәрә.

Үтәү срогы: тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча мәгълүмат урнаштыру.

Эш нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган планнан тыш күчмә тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат.

5.53. Вәкаләтле вазыйфаи зат тиешле мәгълүматны 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.[3] статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә Бердәм тикшерүләр реестрына кертә.

**“Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара аралашмыйча контроль чараларын уздыру” административ процедурасы**

5.54. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара аралашмыйча контроль чараларын уздыруга министр, министр урынбасары тарафыннан раслана торган йөкләмә (алга таба - йөкләмә) административ процедура башлау өчен нигез була.

5.55. Йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге, юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара аралашмыйча контроль чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе Министрлык тарафыннан билгеләнә.

5.56. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча контроль чараларын уздыру өчен җаваплы вазыйфаи затлар – йөкләмәдә күрсәтелгән вазыйфаи затлар була.

5.57. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча контроль д чараларын уздыру срогы йөкләмәдә билгеләнә.

5.58. Йөкләмә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында түбәндәге мәгълүмат нигезендә төзелә:

а) гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан нәселле терлекчелек өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозу турында кергән мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан кергән мәгълүмат;

б) тикшерүләр актларындагы, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшерүләр актларындагы һәм бүтән башкарма документлардагы мәгълүмат.

5.59. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча уздырыла торган контроль чараларына түбәндәгеләр керә:

1) “Интернет” челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырганда мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

2) юридик затның һәм шәхси эшкуарның эшчәнлеге яки гамәлләре турындагы мәгълүматны анализлау ярдәмендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, ул бу затлар тарафыннан федераль законнар һәм Россия Федерациясенең шулар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актлары нигезендә Министрлыкка (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларын куллану юлы белән) тапшырыла яисә федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең шулар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында каралмаган йөкләмәләрне юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга йөкләмичә (шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында) Министрлык тарафыннан алынырга да мөмкин;

3) федераль законнарда билгеләнгән контроль чараларының башка төрләре һәм рәвешләре.

5.60. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча контроль чараларын үткәргәндә җаваплы башкаручы:

1) юридик затлар, шәхси эшкуарлар исемлекләрен әзерли;

2) документлар һәм материаллар җыюны башкара;

3) документларны һәм материалларны эшкәртә һәм анализлый;

4) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча контроль чараларын уздыру нәтиҗәләре буенча документлар әзерли.

5.61. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча контроль чараларын уздыру нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы тиешле хисап әзерли.

5.62. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча мәҗбүри таләпләрне бозуларга карата контроль чараларын уздырганда, вазыйфаи затлар үз компетенциясе чикләрендә мондый хокук бозуларны булдырмау буенча чаралар күрәләр, шулай ук министрга яисә министр урынбасарына әлеге Регламентның 2.13 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү билгеләү зарурлыгы булганда, бу хакта карар кабул итү өчен ачыкланган хокук бозулар турында мәгълүмат белән язма рәвештә министрга яисә министр урынбасарына тәкъдим кертә.

5.63. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча контроль чараларын уздыру барышында булачак хокук бозулар яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр алынган очракта, Министрлык юридик затка, шәхси эшкуарга әлеге Регламентның 3.3, 3.4 пунктлары нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуны булдырмау турында кисәтү җибәрә.

5.64. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән аралашмыйча уздырылган контроль чаралар нәтиҗәләре Министрлык тарафыннан план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр планлаштырганда һәм уздырганда кулланыла.

## 6. Дәүләт функциясе үтәлешен контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

6.1. Министрлык вазыйфаи затларның үз хезмәт бурычларын үтәвен контрольдә тота, тикшерүләр барышында вазыйфаи затларның үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәвен исәпкә алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм мондый вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

6.2. Әлеге Регламентның үтәлешен контрольдә тоту министр урынбасары тарафыннан башкарыла.

6.3. Әлеге Регламент нигезендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча гамәлләрнең сроклары үтәлешен, эзлеклелеген, Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан карарлар кабул итүне контрольдә тотуны министр урынбасары гамәлгә ашыра.

6.4. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга агымдагы контрольне башкаручы вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге, әлеге контрольне гамәлгә ашыру тәртибе һәм даимилеге Министрлык актлары белән билгеләнә. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыру өчен вазыйфаи затларның вәкаләтләре структур бүлекчәләр, дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары турындагы нигезләмәләрдә билгеләнә.

